РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2016 елның 28 июле № 28**

## "Түбән Кама шәһәренең Мактаулы гражданины» исемен бирү турында

«Түбән Кама шәһәренең Мактаулы гражданины» исеме турындагы Нигезләмәгә таянып, Түбән Кама шәһәре мэры А. Р. Метшинның тәкъдимнәрен, предприятиеләр, иҗтимагый оешмаларның үтенечләрен карап, «Түбән Кама шәһәренең Мактаулы гражданины» исемен Түбән Кама шәһәре үсешенә зур өлеш керткән гражданнарга һәм шәһәрнең 50 еллыгы уңаеннан, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

«Түбән Кама шәһәренең Мактаулы гражданины» исемен бирергә:

«Татэнергострой» ААҖ ветераны Абделхакимов Рәшит Валеевичка - Түбән Кама шәһәренең мөһим сәнәгать һәм социаль әһәмияткә ия объектлар төзүгә керткән өлеше, җәмәгать тормышында актив катнашуы өчен;

Сугыш, хезмәт, кораллы көчләр һәм хокук саклау органнарының ветераннар советы рәисе Китанов Григорий Леонидовичка - Түбән Кама муниципаль районында җирле үзидарәне торгызуга, яшь буынга хәрби-патриотик һәм әхлакый тәрбия бирүгә керткән өлеше, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен;

Бөек Ватан сугышында катнашучы, Түбән Кама электр челтәрләренең беренче җитәкчесе Лукшин Валентин Васильевичка - Түбән Кама шәһәре төзелешенә, шәһәрнең социаль-икътисади үсешенә, аның энергетика комплексын үстерүгә зур өлеш керткән өчен;

халык уен кораллары оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм дирижеры Плетнева Зинаида Ивановнага - Түбән Кама шәһәрендә мәдәният үсешенә зур өлеш керткәне, үсеп килүче буынга музыкаль-эстетик тәрбия бирү өлкәсендә актив мәгърифәтчелек эше, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен;

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм архитектура идарәсе башлыгы Ханов Фирдәвес Гайнетҗан улына - Түбән Кама шәһәрендә социаль әһәмиятле объектларны проектлауга һәм төзүгә зур өлеш керткәне, шәһәрнең иҗтимагый тормышында актив катнашканы өчен;

«Татэнергострой» ААҖ, «Камэнергостройпром» ҖЧҖ ветераны Ягудин Әхмәтвәгыйз Әхмәди улына - Түбән Кама шәһәренең социаль-икътисади үсешенә, мөһим сәнәгать объектлары һәм социаль инфраструктура объектлары төзелешенә зур өлеш керткәне өчен.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин